СОВЕТ ГОРОДА ЗАИНСКА
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Орджоникидзе, д. 49, г.Заинск, 423522

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЗӘЙ ШӘҺӘР СОВЕТЫ
Орджоникидзе ур.,49 йорт, Зәй шәһәре,423522

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

27.12.2021 г. Заинск № 76

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәрендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында» 2014 елның 14 ноябрендәге 185 номерлы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән кабул ителгән «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» нигезендә, Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәрендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында» 2014 елның 14 ноябрендәге 185 номерлы Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 14 статьяның 1 өлешендә:

1) 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) Россия Федерациясе гражданлыгы, аның нигезендә чит ил гражданы муниципаль хезмәттә булырга хокук бирә торган Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгы (подданство) туктатылу турында язмача рәвештә муниципаль хезмәткәргә бу хакта билгеле булган көндә, әмма Россия Федерациясе гражданлыгы яисә чит ил гражданлыгы (подданство) туктатылган көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә;»;

2) түбәндәге эчтәлекле 9.1 пункт өстәргә:

«9.1) яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) чит ил гражданлыгы (подданствосы) алу яисә гражданның чит ил дәүләте территориясендә даими яшәү хокукын раслаучы башка документ алуы турында муниципаль хезмәткәргә бу хакта билгеле булган көндә, әмма чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) алган яисә чит ил территориясендә гражданның даими яшәү хокукын раслаучы башка документ алган көннән башлап биш көннән дә соңга калмыйча хәбәр итәргә;»;

1.2. 15 статьяның 1 өлешендә:

а) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) Россия Федерациясе гражданлыгы яисә аның нигезендә чит ил гражданы муниципаль хезмәттә булырга хокук бирә торган Россия Федерациясе халыкара шартнамәсендә катнашучы чит ил гражданлыгы туктатылу;»;

б) 7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә башкасы каралмаган булса, чит дәүләт гражданлыгы (подданствосы) яисә яшәү өчен рөхсәт яисә чит ил территориясендә гражданның даими яшәү хокукын раслый торган башка документы булу;»;

1.3. 24 статьяның 1 өлешендәге 2 пункты үз көчен югалткан дип танырга.

2. Зәй муниципаль районы Зәй шәһәре Советының оештыру бүлегенә әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Зәй шәһәре башлыгы урынбасары Е.В. Недошивинага йөкләргә.

**Совет Рәисе** **Р.Г. Кәримов**